

**Тема: үз үлчәмендә дөнья чемпионы Булат Вәлиев.**

**Әзерләде: Тойгелде төп гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Халимов Аяз Марат улы .**

**Җитәкче: Давлетова Рушания Фатих кызы.**




Спорт белән дус булган кешенең үз-үзенә ышанычы арта, яшәү дәрте көчәя, ул җәмгыятьтә үз урыныңны табарга да булыша. Минем сезне тормышта үз урынын тапкан, соңгы сулышына кадәр аңа тугры булган, шәхес белән таныштырып китәргә телим. Үз үлчәмендә дөнья чемпионы Булат Вәлиев

**Ирешкән уңышлары:**

**1998 елда Әлмәт физкультура техникумы диплом белән бүләкли.**

**1999 елда Әлмәт шәһәре җыелма командасы составына алына. Әлмәт шәһәре беренчелегенә уздырылган ярышта җинеп диплом ала.**

**1999 елның апрель аенда Актаныш башлыгы призына лаеклы булла.**

**Мөслим районында Әмирхан Дәүләтшин исемендәге призга татарча көрәш буенча үз авырлыгында беренчелекне ала.**

**2001 елда Әлмәт районында кышкы спартакиадада беренче урын ала**

**Мөслим районында Илгиз Сахабутдинов призына ярышларда беренче урын ала.**

**Чистайда республика күләмендә уздырылган ярышта беренче урын ала.**

**Әлмәт шәһәре көненә багышлап уздырылган ярышта беренче урын ала һәм гамота белән бүләкләнә.**

**2002 елда Әлмәт районы беренчелегенә үткәрелгән ярышларда беренче урын ала.**

**Түбән Камада уздырылган танылган спорт остасы Данил Галиев истәлегенә багышланган ярышта 3 урын ала.**

**Әлмәт районы буенча үткәрелгән кышкы спартакиада ярышларында беренче урынга лаек була.**

**Мөслим районы беренчелегендә җиңә.**

**Чирмешән районында татар-башкорт көрәшләре буенча ярышта икенче урын ала.**
**Әлмәттә «Нефтяник» газетасы призына уздырылган ярышта беренче урын ала.**
**Азнакай шәһәрендә танылган көрәшче Галиев Фәрит призына үткәрелгән ярышта икенче урын ала.**
**Норлат шәһәрендә уздырылган ОАО «Татнефть»нең XV спартакиадасында икенче урын ала.**
**2004 елда татарстан Республиксы Мәгариф министрлыгы Татарстан педагоглары арасында уздырылган «Аргамак» уеннарында беренче урын ала.**
**Чиләбедә Сабантуй бәйрәмендә татарча көрәш буенча беренче урын ала.**
**Татарстан Республикасы чемпионатында беренче урын яулый.**
**Әлмәттә «Нефтяник» газетасы призына уздырылган ярышта беренче урын ала.**
**Түбән Камада уздырылган танылган спорт остасы Данил Галиев истәлегенә багышлап үткәрелгән Россия турнирында беренче урынга лаек булла.**
**«Ватаным Татарстан» газетасының Муса Җәлил исемендәге зур призга татарча көрәш ярышларында өченче урын ала.**
**Спорт мастеры исеменә лаек була.**







**2005 елда Казанда үткәрелгән билбау көрәше буенча дөнья чемпионатында 75 килограммга кадәр авырлыкта 1 урынны яулап, алтын медальгә лаек була.**

**Булат Валиевны Республикабыз беренче Президенты Минтимер Шаймиев үз янына Кремльгә чакырып тәбрикли, кулын кысып, уңышлар теләп, кыйммәтле бүләкләр тапшыра.**


**2006 елның декабрь аенда Булат Валиев фаҗигале төстә вафат була.**


**Нәсел-ыруның лаеклы дәвамчысы булган кеше ил-Ватан каршында да мәртәбәле, хөрмәткә лаек була.**









***Ана кеше үзенең бөтен гомерен, күңел байлыгын, матурлыгын үз балаларына бирә. Пәйгамбәребез ана хакы турында мондый хәдис әйткән:” Әүвәл анаң, аннан соң анаң, аннан соң да анаң, аннан соң гына атаң”! Ананың йөрәге үлгәнче, балам диеп тибә, гомере буе баласы өчен яши.***








**Булат абый – безнең йөрәкләрдә.**